ГЛАВА УРУССИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с. Старые Уруссу, ул. Советская,
д.16в, 423960

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Иске Урыссу авылы, Совет урамы,
16в йорт, 423960

Тел.: (85593) 4-42-31, факс: 4-41-52, e-mail: Uruss.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
N 3 14 ноябрь 2023 ел

2024 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Какылы-Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 7 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Уставының 14, 81 маддәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге Советының 2019 елның 28 октябрендәге 14 санлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында»гы нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2023 елның 25 ноябрендә 13.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Какылы-Күл торак пункты, Елга урамы, 18А йорт адресы буенча урнашкан КФҮ бинасында, 2024 елда Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Какылы-Күл торак пунктында гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

"2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу авыл җирлегенең Какылы-Күл торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, Бөек Ватан сугышында катнашучы тол калган хатыннардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә сез ризамы:

- зираттагы агачларны кисү (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- торак пункт эчендәге юлларны карап тоту (грейдирлаштыру, юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Урыссу авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, кабул ителгәннән соң 5 көн дәвамында Ютазы муниципаль

районының рәсми сайтында (http://yutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (реер//pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

Ютазы муниципаль районы
Урыссу авыл җирлеге башлыгы Ф.Г. Әминова